**“ФИКСИКИ» мультфильмы – ТАТАРЧА!**

**Сабыйларның яраткан “ФИКСИКИ” мультфильмы Тукай телендә сөйләшә башлады! Татар телендә “Фиксиләр” дип аталган мультфильмны бөтен Татарстан балалары карый алачак.**

Нәкъ менә әлеге мультфильмның сайлап алынуы да юкка түгел. Чөнки “Фиксиләр” популяр, балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килә, сабыйларны җәлеп итә.

60 сериядән торган мультфильмның һәрбер сериясе 5-6 минут чамасы бара. “А кто такие Фиксики? Большой – большой секрет!” дип җырлаучылар хәзер “Ә кемнәр соң ул Фиксиләр? Әйдә әле, сер булсын!” дип җырлый.

Әлеге мультфильм “Аксу” студиясендә тәрҗемә ителгән.

Проектның мөхәррире - Рабит Батулла.

“Фиксиләр”не татарча “сөйләштерүдә” Хәлим Җәләй, Рәмзия Фәйзуллина, Гүзәл Сибгатуллина кебек артистлар катнаша.

Мультсериалның төп үзенчәлеге - текстның шигъри формада булуында. Монда да коллектив белән эшләү ярдәмгә килгән: Разил Вәлиев, Рабит Батулла, Айдар Минһаҗев зур булышлык күрсәткән.

**“Фиксиләр” мультфильмының татарча вариантын Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында карарга мөмкин.**

**http:// mon.tatarstan.ru/rus/fiksilar-serial.htm**

